СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2021 елның 28 октябре № 12/5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты турында» 2005 елның 30 декабрендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына (2006 елның 17 октябрендәге 11/9 номерлы, 23.09.2008 ел, № 34/4, 17.12.2010 ел, № 4/1, 15.02.2012 № 17/2, 19.12.2014 № 46/7, 16.06.2015 № 50/8, 02.11.2015 № 3/3, 17.06.2016 № 9/3, 31.01.2017 №14/8, 07.03.2018 № 25/4, № 25/4, 30.03.2018 № 26/7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге структурасына «баш белгеч – административ комиссиянең секретаре» вазыйфасын кертергә;

2) мәгариф бүлеге структурасына «- баш белгеч – балигъ булмаганнар эшләрен һәм аларның хокукларын яклау Комиссиясенең секретаре» вазыйфасын кертергә;

3) муниципаль заказ бүлеге структурасында «- машина йөртүче» вазыйфасын төшереп калдырырга;

4) оештыру-кадрлар эше бүлеге структурасына «- машина йөртүче» вазыйфасын кертергә;

5) архив бүлеген бетерергә;

6) «архив бүлеге начальнигы» вазыйфасын төшереп калдырырга;

7) архив секторын булдырырга һәм аның структурасын расларга:

«- архив секторы мөдире».

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы,Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров